# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең  Бакча Сарай поселогында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2024 елның 27 ноябреннән №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге  Бакча Сарай поселогындагы гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча Сарай авылындагы торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны  1 төркем инвалидлар;  РФ Саклану министрлыгы белән контракт төзегән СВО зонасына мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары (РФ Гаилә кодексының 2 ст. нигезендә), ә шулай ук башка ведомстволар (Росгвардия, ЧВК, РЖД һ.б.) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш (РФ Гаилә кодексының 2 ст. нигезендә)500 сум күләмендә кертергә. Түләүләр күләме түбәндәге категория гражданнар өчен гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә: күпбалалы гаиләләр; көндезге уку йортлары студентлары; чакырылыш буенча ашыгыч хәрби хезмәт узучылар; тыл хезмәтчәннәре.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Каримов